РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422370 г.Тетюши, ул.Малкина, 39

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур, 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702097, ОГРН 1061672000037, ИНН/КПП 1638004978/163801001

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**02.09.2020** **№ 54-8**

**Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлек башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, контроль-хисап органнары рәисләренең һәм Тәтеш муниципаль районы буенча муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләүләре күләмнәрен арттыру турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы карары нигезендә “Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләүләре күләмнәрен арттыру турында” Тәтеш муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, Тәтеш муниципаль районы буенча контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата түләүләре күләмен 2020 елның 1 октябреннән 1,03 тапкырга арттырырга, “Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында” Тәтеш муниципаль районы Советының 2018 елның 17 апрелендәге 30-3 номерлы карары белән (Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Советының 2018 елның 22 маендагы 31-2 номерлы, 2018 елның 27 августындагы 33-4 номерлы, 2018 елның 26 ноябрендәге 35-5 номерлы үзгәрешләр кертелгән карарлары белән) расланган.

2. 2020 елның 1 октябреннән Тәтеш муниципаль районы буенча муниципаль хезмәткәрләрнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында 2018 елның 17 апрелендәге 30-3 номерлы Тәтеш муниципаль районы Советы карары (Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Советының 2018 елның 22 маендагы 31-2 номерлы, 2018 елның 27 августындагы 33-4 номерлы, 2018 елның 26 ноябрендәге 35-5 номерлы үзгәрешләр кертелгән карарлары) белән билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәт вазыйфалары окладлары күләмнәрен арттырырга.

3. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен исәпләү өчен, әлеге карарның 2 пункты нигезендә, авыл җирлегендә муниципаль хезмәт

вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының күләмен 1,03 тапкыр индексацияләргә һәм аны 11 498 сум күләмендә билгеләргә.

4. Әлеге карарны реализацияләү белән бәйле чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының җирле бюджетларында каралган бюджет ассигнованиеләре кысаларында гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга

6. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**башлыгы** **Р.Х. Сафиуллов**